**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ**

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**23 нче сентябрь 2020 ел** **№ 4**

**Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 220 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәткә түләү һәм акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 нче номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре күләмен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 220 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәткә түләү һәм акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» карары белән расланган Биектау муниципаль районы башлыгының, Биектау муниципаль районы башлыгы урынбасарының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата хезмәт хакының күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 220 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәткә түләү һәм акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи

окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» карары белән расланган тәртиптә билгеләнә торган Биектау муниципаль районындагы муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә 2020 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Әлеге Карарның 2 пункты нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,03 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11498 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 220 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәткә түләү һәм акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» карары белән расланган 1 һәм 2 нче номерлы кушымталарны, таблицаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары,

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 30442 |
| Муниципаль район Башлыгының урынбасары | 27398 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы рәисе | 27398 |

.»;

б) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре,

| N т/б | Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|
| | | 8 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 29895 |
| 2. | Совет аппараты җитәкчесе | 27135 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 26906 |
| 4. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 26790 |
| 5. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 24606 |
| 6. | Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр белән идарә итүче) | 25180 |
| 7. | Башкарма комитет аппараты идарәсе начальнигы | 21846 |
| 8. | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлекчәсе начальнигы (мөдир), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе | 20927 |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Башкарма комитет аппараты идарәсе начальнигы урынбасары | 20697 |
| 10. | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлекчәсе начальнигының (мөдире) урынбасары, башка структур бүлекчәсе җитәкчесенең урынбасары | 18283 |
| 11. | Муниципаль район Башлыгының ярдәмчесе | 18283 |
| 12. | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек начальнигы | 18283 |
| 13. | Сектор мөдире | 16902 |
| 14. | Баш белгеч | 16212 |
| 15. | Әйдәп баручы белгеч | 15063 |

.».

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанслар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе
Муниципаль районы Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин